# Нәсыйхәт

Җомга
25
апрель
2014
№27

**Рәхимле вә Шәфкатьле АЛЛАҺ исеме белән**
**Мамадыш мәдрәсәсенең айлык дини-иҗтимагый газетасы**


## Яңалыклар

### ХӘЗРӘТ ҖОМГА НАМАЗЫНДА

Мәдрәсә мөгаллимнәре тарафыннан авыл мәчетләрендә җомга намазлары укытыла. Әлеге чараның максаты авылларда халыкның дин белән кызыксынуын арттыру, имамнар белән аралашу, мәдрәсәгә яңа шәкертләр җәлеп итү. Чираттагы җомга Габдрахман хәзрәт тарафыннан “Изге Нур“ мәчетендә үткәрелде.

### КАЗАНГА КУРСЛАРГА

Мәдрәсә җитәкчесе Габдрахман Хәбибуллин 30 апрель көнне Россия Ислам Институтында узачак эшлекле җыелышта катнаша. Җыелышта мәгариф министрлыгында эксперт вазыйфасын башкаручы Рөстәм Хәйбрахманов белән очрашу көтелә. Очрашуда мәдрәсәләрне лицензияләү һәм уку йортларында яңа стандарт мәсьәләсе кузгатылачак.

### АВЫЛЛАР БУЕНЧА

Мамадыш мәдрәсәсе укытучылары авыллар буенча йөрүне дәвам итә. Бу эшнең максаты районнарыбызда белемле, тиешле дәрәҗәле имамнар, Ислам нигезләренә өйрәтүче укытучылар һәм башка дин белгечләрен булдыру. Шул исәптән Мамадыш мәдрәсәсе вәкилләре тарафыннан район авыллары, мәктәпләре һәм мәчетләре буенча таныштыру-чакыру эшләре алып барыла.

### ИМТИХАННАР ЯКЫНЛАША

Мамадыш мәдрәсәсендә уку елы ахырына якынлаша. 12нче майдан мәдрәсәдә имтиханнар һәм зачетлар башланып китәчәк. Быел мәдрәсәне 21 шәкерт тәмамлаячак. Имтихан нәтиҗәләренә карап, аларга дипломнар тапшырылачак.

### ҖӘЙГЕ ҖӘЙЛӘҮЛӘР

2нче июньнән алып 21 көн дәверендә Мамадыш мәдрәсәсендә җәйге җәйләүләр узачак. Ул сменалап булыр дип көтелә. Белешмәләр өчен телефон. 89172802391; 3-19-17

# «НИКАХ - МИНЕМ СӨННӘТЕМ»



Аллаһка шөкер, җәмгыятебездә Исламны тормыш рәвеше итеп кабул итүчеләрнең саны арткannan-арта бара. Шуңа да соңгы елларда шәһәребездә мәчет, мәдрәсәгә йөрүчеләрнең саны күбәя. Шәһәребездә оешкан “Ак калфак” мөслимәләр оешмасы нәтиҗәле генә эшләп килә. Ислам дине фәкать гыйбадәт кылуны гына күздә тотмый. Мөселманнар спорт белән дә мавыгалар, конкурслар, бәйрәмнәрне дә зурлап уздыралар. Аларның барлык гамәлләре дә, Аллаһы Тәгалә кушканча, хәләл юл белән башкарыла. Гаилә кору мәсьәләсе дә шушы ук принциптан чыгып хәл ителә. Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгалә “Нур” сүрәсендә әйткәнчә: **“Буйдакларны, колларыгыздан, жарияләрегездән булганнарны өйләндерегез, кияүгә бирегез. Фәкыйрь булганнарны Аллаһ үз нигъмәтләре белән баетыр, иншә Аллаһ. Нигъмәтләре мул булган һәм бар нәрсәне дә белеп торучы Ул (Аллаһ)”.** Мөселман гаиләсе ничек барлыкка килә соң? Иң таралган ысул - танышлар, туган-тумачалар аша. Ләкин мөселман туганнарың булмаган очракта нәрсә эшләргә? Бу очракта ярдәмгә танышу үзәкләре ярдәмгә килә. Аллаһының рәхмәте белән, “Ак калфак” мөслимәләр оешмасы моның белән шөгыльләнә башлады. Аның җитәкчесе **Рузалия ИБРАҺИМОВА** белән әңгәмә корабыз.

**–Рузалия ханым, әлеге кирәкле эш кайчан һәм нинди максат белән оештырылды?**

–Җир йөзенә килгән сәламәт акыллы кеше гаилә корып, үзеннән соң буыннар калдырырга тиеш. Һәркемнең никах сәгате билгеләп куелган һәм ул үзгәрми. Әязмышны без үзебез язабыз. Чая-үткеннәр үзләренең ярларын тизрәк табып, гаилә коралар, оялчан, тыйнак мөселман яшьләр ялгыз калырга да мөмкин. Очрашып, күрешү, танышу мөмкинлеге аз булып, гаилә кормаганнар күп булганлыктан без, “Ак калфак” оешмасыннан берничә кеше берләшеп 25-50 яшькә кадәр булган хатын-кыз һәм ир-егетләрне кавыштыру түгел, ә бер-берсе белән таныштыруны максат итеп куйдык. Инде үзегезгә тиң насыйп булган ярны очратып, гаилә корасыз икән ,бәхет телибез.

**–Таныштыру эше ничек оештырылачак?**

Үзәккә килүче һәрбер кеше үзе турында мәгълүмат бирә, анкета тутырыла. Анкеталарны өйрәнгәннән соң, җавапларга туры килердәй респондентлар белән таныштырырга ниятлибез. Мөселман кардәшләребезне язган мәгълүматлар чит кешеләр арасында таратылмаячак дип ышандырабыз.

Җыелган анкеталарны тикшереп, өйрәнеп, холкы, дини гыйлеме буенча якын булган кешеләрне бер-берсе белән очраштырабыз. Әлбәттә, очрашу шаһитлар барында уза. Очрашуга килүчеләргә хәзрәт никахның әһәмияте турында вәгазь сөйли. Динебезнең төп кануннары белән таныштыра. Очрашудан соң танышуга килүчеләр өйләренә таралыша. Икеләнгән очракта мөселманнар “Истихара” намазын укып, Аллаһы Тәгаләдән дөрес һәм хәерле юлны күрсәтүдә ярдәм сорыйлар. Аллаһы Тәгалә насыйп итсә, парлар кавышалар.

**–Рузалия ханым, гаилә корырга ниятләгән газета укучыларга нинди теләкләрегезне җиткерер идегез?**

–Никах нигезе - Аллаһыга итагать кылуны аңлата. Пәйгамбәр галәйһиссәламнән риваять ителгән: “Никах - минем сөннәтем. Шуңа күрә, кем минем сөннәтемнән баш тартса, ул минем өммәтемнән түгел. Никахлашучы ир – омтылучы, никахлашучы хатын – омтылыш сәбәбе. Мөһер икесенең килешүенә таянып билгеләнә. Никахлашыгыз, балалар табыгыз, күбәегез. Ник дисәгез, мин Кыямәт көнендә сезнең белән бүтән өммәтләр каршында горурланачакмын”, – дигән.

Әгәр дә гамәлнең нигезенә Аллаһы Тәгаләгә буйсынып яшәү ятса, димәк, бу гаиләнең киләчәге ышанычлы, рухы сәламәт, үзара әдәпле, йомшак мөнәсәбәтләр булуына ышаныч бар. Гаилә җанга тынычлык бирә торган урын булырга тиеш.

**-Әңгәмәгез өчен рәхмәт, Рузалия ханым.**

**Әңгәмәне Фирая МИНГАЛИЕВА үткәрде**

**(Анкета сораулары газетабызның 4нче битендә)**

# Җимерелгән өйгә ошаган

**Тулаем Коръәнне ятлап, аны йөрәгендә саклаган кеше "хафиз" диеп атала. Кемдер әйтергә мөмкин, бу һич тә мөмкин эш түгел, яисә бик тә авыр дип. Юк, бу алай түгел. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә әйтә: "Дөреслектә, без сезгә Коръәнне иңдердек, һәм без аны үзебез саклаячакбыз". Сүрә " Әль- Хиҗрә", 9 аять. Икенче аятьта болай диелә: "Аллаһ Тәгалә кешегә кулыннан килмәгәнне йөкләми". Сүрә " Сыер" 286 аять. Махфузулла. Таҗикстаннан. 22 яшь. Казанда Коръән укучылар һәм Изге китапны яттан белүчеләрнең (Коръән - хафизлар) республика бәйгесенең 2010, 2012, 2013 елларда җиңүчесе. Шулай ук " Зәйтүнә" II республикакүләм дин мөнәҗәтләр фестивалендә группа белән катнашып җиңүчеләр арасында. "Мөхәммәдия" мәдрәсәсендә Коръән фәнен укыта. Коръән хафизлар нинди булырга тиешлеге турында без ишетеп, укып беләбез. Аны ятлап бетереп, үз йөрәгендә ничә еллар саклап торучы егет белән әңгәмә корып алыйк. Димәк, киттек.**

**-Кайчан һәм ничек Коръәнне ятлый башладың?**

- Балачактан ук ятлый башладым. Инде 2 класста 3 җүз белә идем. Әмма дә ләкин Коръән ятлау белән шөгыльләнермен диеп уйламаган идем. Ул вакытта мин остазга йөреп әхлак, гакыйдә фәннәрен өйрәнә идем. Бервакыт минем укытучым авырып китте. Мин шул вакытта Коръән белән җитди шөгыльләнә башладым.

**- Кемдер тәкъдиме, яисә үзеңнең теләк белән тотындың бу зур эшкә?**

- Кемнедер мәҗбүриләп Коръән ятлаталар икән, ул хафиз булып җитешмәячәк. Мин үзем шундый мисаллар беләм, физик көч кулланганда балалар Коръән хафиз булып чыкмадылар. Яхшы нәтиҗә, үзең яхшылап тырышканда, көч куйганда гына булачак. Бәләкәй балаларга уку вакытында үзеңнең йомшаклыгыңны күрсәтмәскә, алар бу вакытта тырышлыкларын югалтырга мөмкиннәр. 15 яшьтән узганнар инде үз көчләрен куеп, тырышырга тиешләр.

Аллаһы Тәгалә бөтен кешегә дә Коръәнне аңларга һәм аны өйрәнергә мөмкинчелек бирми. Бөтен кеше дә җиңел генә хафиз була алса, Коръәнгә хөрмәт калмас иде. Хафиз булу өчен бик күп имтиханнарны үтәргә кирәк. Шул сынауларны үтсәң генә Аллаһ сиңа Коръәнне бирә. Гөнаһ гамәлләр күбрәк кылган саен, Коръән истә калмый. Чөнки күпләрнең башлары дөнья мәшәкатьләре белән тулган.

**-Коръәнне махсус методлар белән өйрәнде гезме?**

- Әлбәттә, төрле методлар бар. Кемдер бер битне бик күп тапкыр укый (100-300), ә мин берешәр аятьләп өйрәнү белән ятладым. Минемчә, болай ятлау җиңелрәк. Иртә белән ятлап, кич белән кабатласаң, ятлаганың озаграк истә тора. Ятладың да, калдырдың түгел, ә һәрдаим кабатлап тору лязем.

**-Ашауга килсәк, нинди ризыкларга өстенлек бирергә?**

-Иртә белән сөт эчәргә тәкъдим итәр идем. Күп итеп ашау сәгать уннарга башны йоклау халәтенә китерә. Шуннан соң баш ялкаулана. Ә төшке ашта туклыклы ризыклар ашау бик тә мәслихәт. Чөнки өйлә намазы укыла, аннан соң ял итеп аласың. Кичкә шулай ук яхшылап ашарга рөхсәт ителә. Шунысы бар, Коръән ятлаганда кешенең карыны тиз ача. Әмма бу зыянлы түгел. Коръән кешегә дару кебек тәэсир итә.

**- Хафиз булганнан соң, көнгә ничә җүз кабатлау кирәк?**

- Иң кимендә бер җүз кабатлау кирәк. Кабатлау өчен яхшы вакытлардан булып иртә һәм кич санала. Коръән өчен аерым бер вакыт кирәк түгел үзе, аны һәрвакыт кабатлау, ачып тору кирәк. 24 сәгать кешегә болай гына бирелмәгән.

**- Коръән ятлаудан башка хафизлар ниләр белән шөгыльләнәләр?**

- Әлбәттә алар гатәти кешеләр кебек төрле эшләр белән шөгыльләнәләр. Спорт, ял итү дисеңме. Шунысы мөһим, пәйгамбәребезнең сөннәтен яхшылап үтәү аларның тормышында зур урын алып торырга тиеш. Иртәнге, кичке догаларны уку, әхлак кагыйдәләрен үтәү кебек. Никадәр сөннәт гамәлләрне күбрәк үтисең, шулкадәр хәтерләү сәләте яхшыра. Ә кирәкмәгән сүзләр сөйләү, гамәлләр кылу хәтерне начарайта. Шуңа күрә Коръәнне ятлау да авырлаша.

**- Коръән ятлауга музыка күпме зыян китерә?**

-Коръән ятлаучыга музыка тыңлау катгый тыела. Ә мөнәҗәт, нашидлар тыңлау рөхсәт ителә. Әлбәттә алар Аллаһны, пәйгамбәребезне искә төшерергә сәбәп булсалар.

**- Үзең башка хафизлар белән аралашасыңмы соң?**

-Әйе. Без укыганда 40 идек. Студентлар Россиядән, Үзбәкстан, Ингушетиядән дә бар иде. Бергә уку җирендә яшәдек, ашадык дигәндәй. (Таҗикстанда)

**- Синең өчен бу фани дөнья нәрсә ул?**

- Коръәнне ятлаганчы бу дөньяны мин гомумән башкача күрә, аңлый идем. Аннан соң, минем өчен дөнья башка төс алды. Һәрвакыт Аллаһны үзең янында тоясың, аның рәхмәте син кайда гына булсаң да ирешеп тора. Башка илләргә китсәң дә күңелең тыныч.

**- Коръәнне ятлап та, Аллаһ кануннары буенча яшәмәүчеләргә нәрсә әйтер идең?**

- Әлхәмдүлиллаһ, бүгенге көндә Коръән хафизлар күп. Аллаһ кануннары буенча яшәмәүчеләр, димәк бу дөнья өчен, кеше күрсен дип тырышканнар. Бу зур нигъмәт Аллаһтан. Аның әркәннәрен үтәмәүчеләр, әлбәттә, Аллаһ каршында Кыямәт көнендә җавап бирәчәкләр.

**- Хәдис шәрифтә әйтелә: "Җәннәткә беренче керүче кеше- ул Коръән хафиз, тәмугка беренче керүче дә- Коръән хафиз"-диеп.**

-Ният зур урын үйный. Әгәр дә дөрес ният куелмаган булса, кеше Мәккәгә барып Коръән ятлап кайтса, Казанга кайткач онытачак. Шундыйлар да бар, Коръәнне укыганда тегендә-монда йөреп укыйлар, бу зур тәртипсезлек һәм хөрмәтсезлекне күрсәтә. Коръәннән бер генә хәреф уку да, изге гамәл булып тора бит. Әгәр кеше авырлыклар белән укый икән, укуын дәвам итсен. Чөнки аңа хафизлардан да күбрәк савап язылачак, ин шә Аллаһ. Шундый хәдис бар: "Коръәннән бер генә хәрефе дә булмаган кеше җимерелгән өйгә тиң." Әт-Тирмизидән килә бу хәдис.

**- Синең матур итеп нашидлар җырлавыңны да беләбез. "Зәйтүнә"II республикакүләм дини мөнәҗәтләр фестивалендә группагыз белән катнашып җиңү дә яуладыгыз. Ничек уйлыйсың, кирәкме мондый ярышлар үткәрү?**

- Синең җырлавыңны халык көткәндә, әгәр дә җырларың Аллаһ юлыннан атлар өчен этәргеч булса, бик яхшы гамәл. Шулай ук исламга мәхәббәт уятулары мөһим. Ә җиңү, урыннар алу өчен ярышу мөселман өчен мөһим булырга тиеш түгел. Җиңү –ул Аллаһ каршында булырга тиеш.

**-Концертлар планлаштырыламы?**

- Әлбәттә, ниятләр бар. 2015 елда Аллаһ теләсә, группабыз белән чыгышларыбыз башланачак. Группабызда дүрт кеше.Продюсерыбыз белән клиплар әзерлибез (Марат Мухин). Мөселман туйларында чыгыш ясарга һәрдаим чакырып торалар. Казан, Мәскәү кебек зур шәһәрләрдә дә.

**- Җылы әңгәмәгез өчен зур рәхмәт! Уңышлар!**

**Сөмбел ШӘРИФУЛЛИНА.**

# Син саф мәхәббәткә лаекмы?

**(Дәвамы. Башы 26нчы санда)**

Иң беренче аяк терәп Иман китерүне һәм Ислам дине нигезендә яшәү рәвешен таләп итәргә кирәк... Алдагы битләрдә аңлатылганча бу акылсыз һәм сукыр мәхәббәт булып кара кайгыга илтәргә мөмкин. Һәм икенчедән сөйгәнеңне (икенче милләттән һәм диннән) Хәлим үә Кәрим булган Аллаһы Тәгаләдән артык яратып Әлмисакны ягъни төп килешү кануннарын аяк астына салып таптау була күрмәсен! Җир йөзендә һәркем Аллаһының барлыгына һәм берлегенә инанып кальбен һәм үзенең бөтен барлыгын (асылын) багышларга тиеш Аллаһ Раббыбызга булган яратуга. Бу ярату ягъни мәхәббәт үзгә буларак ия Бөек Аллаһтан билгеле бер дәрәҗәдә куркуга, ризалыгын сораууга һәм һәртөрле кыенлыклардан бары Аңа гына сыгынуга. Тагы да өстәп әйтәсе килә, башка дин затына булган мәхәббәт бик сирәк очракта гына үзен аклый... Ә ничек ул безнең Хак дингә керә ала? Алдагы язмаларда әйтеп киттек һәр кешенең фитри иман ягъни тумыштан иман белән дөньяга килүен. Галимнәребезнең әйтүе буенча бу фитри иман гына җитми, ә җаныбызның әйтүе буенча ул ягъни фитри иман хакыйкый иман көченә керергә тиеш. Һәр кешенең калебендә хакыйкый иман акыл белән тиешле дәрәҗәдә аңлап һәм аның күңеленә тиешле тәртиптә урнашкан булу турында сүз бара:

-Иман яки шәһәдәт кәлимәсенең мәгънәсен белү;

-кәлимәне әйткәндә аз гына да шикләнмәскә кирәк;

-шәһәдәт кәлимәсен ялганлап әйтү катгый тыела;

-аның мәгънәсенә буйсыну ягъни синең һәр гамәлең Аллаһ Раббыбыз кушканнарын үтәү һәм тыйганнарыннан тыелу;

-аны ихлас күңелдән әйтү;

-Бөек тәхетнең иясе Раббымның кануннарын (хөкемнәрен) кабул итү һәм үтәү;

-Җәнаби Хак Тәгаләне ярату ягъни Аңа чын күңелдән булган тугрылык, Ул биргән һәм Ул аңлаткан әйберләрне ярату.

Ә хәзер, Мөселман булуның иң әһәмиятле шарты (барысы 5 шарты бар), ягъни балигълык яшенә җиткәч, кемдер соңыннан, кемдер Ислам диненә керергә ният кылгач шаһитләр алдында: Лә Иләһә иллаллаһу, Мөхәммәдүррасүлуллаһ ягъни үзебезнең телдә: Юк Илаһ Аллаһыдан башка, Мөхәммәд Аллаһының илчесе дию. Әбү Хәнифә (р.а.г.) өйрәтүе буенча югарыда әйтелгән Иман (шәһәдәт) кәлимәсен күңел белән хаклыгын тану һәм Иман рөкеннәрен (тәфсилле (тулы) иман) өйрәнү юлында булу нигезендә тел белән әйтү. Тел белән әйтү бик тә мөһим санала, чөнки ул калеб белән буйсынуны шаһитләр алдында күрсәтү була дип аңлата Әбү Хәнифә (р.а.г.).

Бүгенге көндә безнең (мөселманнар) өчен иң мөһиме Аллаһы Тәбәракә үә Тәгаләнең "Гыймран" сүрәсенең 103нче аятендә әйтүе буенча: "**... алар дин аша туганнарга әйләнделәр. Бергәләшеп шәригать тирәсендә тупланыгыз һәм аерылмагыз**". Ислам әхлагы (мөселманнарның үзара хокуклары, мөселманнарга гына кагыла торган дуслык, туганлык хокуклары һәм вазыйфалары) һәм иман нигезләре сорауларына иркенләп тукталу мөмкинлеге булмау сәбәпле Әмин (ышанычлы) Пәйгамбәребезнең (с.г.ү.с.) бу сорау буенча бер китап язарлык хәдисенә тукталам: **"Әгәр кеше башка кешегә үзенә теләгәнне теләмәсә, ул чын мөселман була алмый.** Чын дус дустының күңелен яхшыртырга, кальбен (күңелен), рухын төзәтергә омтыла, аны чын, туры юлга алып чыгарга тели. Акыллы кеше үзенә дә, дустына да явызлык теләми. Чын дус авыр чакта дустына Аллаһ хакына игелек күрсәтә, ярдәм итә. Дустында начар сыйфат күрсә, гөнаһка баруын аңласа, аны тыя, туктата. Шатлыкта да, катлаулы хәлләрдә дә ул бер төсле. Әгәр дусты дөрес булмаган эш эшләгәндә дәшмәсә, тыймаса, елмаеп кына торса, артында икейөзлеләнсә – дустын хурласа, бу чын дус түгел! **Әгәр дин мәсьәләләрендә аңлашылмаучылык туса, мәсәлән, берсе шәригать таләбен боза, үзен төзәтергә ашыкмый, тәүбәгә килми, яки, киресенчә, гел яманлыкка бара, дин буенча үз вазыйфаларыннан баш тарта, андый чакта инде эш башкача тора; динебезне яклау мәсьәләсе туа. Мондый очракта шәригать таләпләрен бозучының яман йогынтысы булу ихтималы турында башкаларны кисәтергә тиешле булабыз".** Ни өчен мөселман кардәшлегенә һәм дуслыгына басым ясарга телим, чөнки минә шушы мөнәсәбәт җирлеге генә тугры дуслыкны гына түгел, ә гүзәл затлар һәм ир-егетләр арасында саф мәхәббәткә генә юнәлтергә мөмкинлек туа. Инде мөнәсәбәтләр тугры дуслык нигезендә мәхәббәт юлына аяк баса икән ягъни кичәге икенче җенестәге дустыңны үзеңне генә яраткан һәм кадерләгән кебек (Нарцисс законы) ихтирам һәм хөрмәт итә башлыйсың икән, аның шатлыкларын, борчылуларын, тойгыларын, хисләрен һәм уйларын үзеңнеке кебек кабул итә башлыйсың икән, бу чыннан да саф мәхәббәтнең гыйльме рух нигезе салына башлаганны күрсәтә. Ә хәзер аз гына үзгәртүләр белән кыскача гына гыйльме рух күзлегеннән Нарцисс законына тукталам. Озын сүзнең кыскасы, бу әкият (миф) бик үзенчәлекле һәм бик гыйбрәтле, ягъни тормышыбызда да чагыла үзәкләшкән эгоизм яки эгоизм сыйфатлары аркасында кешенең үзе дә аңламыйча яки күпмедер дәрәҗәдә аңлап һәлакәткә баруы...

Нарцисс бик тә чибәр, салкын һәм горур егет була. Ул үзен генә ярата һәм ул саный мәхәббәткә лаек бердәнбер кеше үзен дип. Аның әтисе елгалар хуҗасы, ә анасы чибәр урман кызы була. Бу егет бервакыт ау вакытында куе урман эчендә адаша. Аны күреп ала урман кызларының берсе Эхо. Бу матур кыз бала Нарцисска гашыйк була. Ә Нарцисс кая барырга белмичә кычкыра:

-Әй, кем бар монда?

-Монда! - дип җавап бирә Эхо.

Ул тирә-якка карый. Беркем дә юк. Яңадан кычкыра:

-Монда, тизрәк минем яныма кил!

Шатлык белән Эхо җавап бирә:

-Яныма кил! - дип Эхо кулларын алга сузып бара егет янына, ә Нарцисс ачу белән чибәр һәм буй җиткән кыз баланы үзеннән кирегә этеп җибәрә һәм куе урман эченә кереп китә... Урман кызы Эхо сагышка бата. Беркемгә дә күренми, беркем белән дә сөйләшми һәм тирән кайгыга бата... Ә Нарцисс әүвәлгечә горур һәм үз-үзенә генә гашыйк булганча кала бирә. Аңа берсеннән-берсе акыллырак һәм чибәррәк кызлар гашыйк булалар. Бервакытны бу кызларның берсе аңа бәддога укый:

-Нарцисс, син яратсаң иде шул кешене, ә ул үзең кебек җавап бирмәсә иде!.. Һәм дә ки бу кыз баланың теләге кабул була. Ике-өч сүз белән генә шуны әйтәсе килә – ләгънәт (бәддога) укудан сак булыгыз! Ни өчен? Аның яртысы үзегезгә кире кайтырга мөмкин. Ләгънәт укыганчы Аллаһ үә Сөбхәнә Тәгаләдән сорарга кирәк түбәндә әйтелгән тәртип белән:

-иң башта Аллаһ Раббыбызга хәмед һәм Пәйгамбәребезгә (с.г.ү.с.) салават әйтеп башларга кирәк;

-мәсәлән, безнең сорау буенча "Йә, Аллаһ Раббым, яраткан егетемнең яки кызымның күңелендә минем саф мәхәббәтемә җавап йөзеннән мәхәббәт миһербанлыгы тудырсаң иде", - дип теләкләр теләү отышлырак;

-ихлас күңелдән хак теләк теләсәң һәм хак динебез юлында булсаң теләкләр кабул булырга мөмкин. Кешелек дөньясының мактанычы Пәйгамбәребез әйткән: "Теләк өч төрле була. Беренчесе үтәлә. Икенчесе сезгә төшеп килгән бәла-каза белән көрәшә. Өченчесе бу дөньяда юк, кеше аның әҗерен кыямәт көнендә күрә".

**КАМИЛ ХИСМӘТОВ, мәдрәсә шәкерте, гер спорты буенча Гиннесс китабы рекордчысы**

**(Дәвамы киләсе саннарда)**

*Югары Сон авылының Ак Әбиләреннән берсе булган, бүгенге көндә 82 яшен ваклап, хәзер дә хәтеренә зарланмыйча, биш вакыт намазын укып, күңеленнән ургып чыккан хисләрен шигъри юллар белән кәгазь битләренә төшереп баручы Вәлимөхәммәт кызы Рауза әбигә сокланмый мөмкин түгел. Үзенә тормыш биргән Әнисенә зур рәхмәтле ул. Бик сирәк кенә чыккалап, күп вакытын өйдә генә уздырса да, туган төбәге өчен хезмәтләрен аямаган җитәкчеләр өчен дога укып, рәхмәтле булып яши. Хәзерге вакытта "аяклы тарих" булган кадерле әбиләрнең берсе. Безгә ул, Югары Сон авылы буенча, буыннар чылбырын барларга да, бик нык ярдәм итте. Аның, соңгы вакытларда гына язган шигырьләрен укыдым да, сезгә дә тәкъдим итәргә булдым.*

**РӘЙСӘ МУЛЛАХМӘТОВА.**

**ХӨСНУЛЛИНА РАУЗА ВӘЛИӘХМӘТ кызы иҗатыннан:**

**Түбән Сон авылы.**

## Әнкәемә

Безнең Әнкәй
бисмиллалы иде,
Бисмилла әйтеп,
таңны башлады.
Бисмилла әйтеп,
тәгам әзерләде,
Тәмле була иде ашлары.
Нәзәкәтьле,
бәрәкәтле икмәгебез.
Суда шифа бетмәс
иншаллаһ.
Яшәвебез имин,
тыныч булыр,
Күңелләрдә булса
бисмилла.
Безнең Әнкәй гайбәт
сөйләмәде,
Нахак сүзләр
өйгә кертмәде.
Гел игелек, гел
яхшылык иде,
Кешеләргә Әнкәм
иткәне.
Мин дә Әнкәй кебек
бисмиллалы
Фатыйхамны
юрыйм киткәндә.
Башым иеп,
сәлам биреп калам,
Янәшәмнән
картлар үткәндә.

**"Иң яхшы шигырь" конкурсына ХАҖИЕВА ӘЛФИРӘ ШӘМСЕМӨХӘММӘТ кызы**

### Никахыгыз хәерле булсын

Бөек Аллаһ җир йөзендә
Бар нәрсәне пар - пар
яраткан.
Берсен - берсе әзләп
табу өчен
Җир йөзенә сипкән,
тараткан.

Бүген сезнең кавышу
көне җитте-
Булыгыз сез сабыр,
бәхетле.
Тәүге никах -
соңгы никах булсын
Сезнең белән тигез
гомерле.
Нәрсә соң ул никах?
- Аллаһ Тәгалә каршында
Бер - береңә биргән
вәгъдәләр.
Гаилә томышына
хәерле юл –
Вәгъдәңнең инде
кадерен бел!
Ант бирдеңме – инде
хәзер үтә!
Тормыш юлың
да бәхетле үтәр.
Вәгъдәләр өч:
Беренчесе -
әти - әниемнең,
Икенчесе –балаларымның
хакын хакларммын.
Өченчесе – иремне - ир
итеп санармын,
Хатынымның хакын
хакларммын.

Шаһитләр каршында
шушы бурычларны
Йөкләмә итеп бүген
алырсыз.
Аллаһ каршында
биргән вәгъдәгезгә
Ахыргача тугры калырсыз.
Бисмиллаһ, - дип,
башлап тормыш юлын,
Никахыгызны
кадерләп саклагыз.
Тормыш үрен менгән
вакытларда
Иңгә иңне куеп атлагыз.
Нәсел дәвамчысы калсын –
Бирсен Аллаһ иманлы
балалар.
Тормышыгыз
булсын түгәрәк,
Күпләр сездән
үрнәк алырлар.



# «НИКАХ - МИНЕМ СӨННӘТЕМ»

**(Башы 1нче биттә)**

## Анкетаның сораулары:

1.Ф.И.О.
2. Туган елың. Аең. Парыңның яшь аермасы күпме булырга мөмкин?
3. Буй озынлыгың. Парыңның синнән озын яки кыска булуы шартмы?
4.Яшәү адресың? Кемнәр белән яшисең? Гаилә корсаң яши торган җиреңдә парың белән бергәләп тормыш кору мөмкинлеге бармы? Яки башка йортка, авылга, шәһәргә парыңның йортына, фатирына күчеп яши алуыңны күз алдына тотасыңмы?
5. Нинди хуҗалык белән яшисең: участогың, машинаң, мал-туарың һәм башкалар.
6.Никахка кергәнең булдымы? Тулы мәгълүмат бир: нинди кеше иде, ни өчен аерылыштыгыз?
7.Балаң (балаларың) бармы, никахта табылганмы, аңа әти-әни кеше алимент түлиме? Балага ничә яшь, кайда, кем белән яши? Башка никахка керсәң бала кем белән яши?
8.Үзеңнең балаң булмаса балалы хатын (ир) кеше белән гаилә коруны күз алдына китерә аласыңмы?
9. Үзеңә тиң ярны иң кирәкле уңай һәм сиңа охшамаган тискәре якларын күрсәт.
10. Нинди кеше белән берничек тә яши алмас идең?
11. Гаилә корсаң кайда яшәүне күз алдында тотасың?
12. Белемең нинди, кайда, кем булып эшлисең?
13. Тормышка карашың? Нинди үзенчәлекле якларың бар? Нәрсә ошый, ошамый? Эчәсеңме, тартасыңмы. Ешмы? Аларга һәм аларны кулланучыларга карашың нинди?
14.Буш вакытыңда нәрсә белән шөгыльләнәсең?
15.Очрашуны кайда, ничек итеп оештыруны телисең? Күмәк очрашуда катнаша алыр идеңме?
16.Мөмкинлек булса анкета белән фотоңны җибәр.
17.Элемтә өчен телефон номерыңны күрсәт.
18.Безнең белән элемтәгә керү телефоны: 8-987-007-95-92.
19.Җавапларны сиңа анкета тапшырган кешегә, яки түбәндәге адрес буенча җибәрә аласың: **Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы, 8\28 йорт, мәдрәсә, "Ак калфак"**

**МАМАДЫШ МӘДРӘСӘСЕНӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!**

Татарстан Җөмһүрияте Мөселманнары Диния Нәзарәте каршындагы Мамадыш мәдрәсәсе 2014-2015нче уку елына шәкертләр туплый.
Белгечләр әзерләү көндезге һәм кичке уку рәвешендә алып барыла. Көндезгә бүлеккә яше 14тән дә ким булмаган егетләр кабул ителә. Шәкертләр мәдрәсә тулай торагында яшәү урыны һәм көненә 3 тапкыр ашау-эчү белән тәэмин ителәләр. Мәдрәсәне тәмамлаганнан соң шәкертләргә квалификация комиссиясе карары нигезендә тиешле белгечлек алу турында диплом бирелә.
Намаз укырга өйрәнергә һәм дин белемен үзләштерергә теләүчеләр өчен мәдрәсәдә кичке уку бүлеге һәм читтән торып уку бүлеге эшли. Бу бүлекләргә хатын-кызлар һәм ир-егетләр кабул ителә. Яшь чиге куелмаган.
**Безнең адрес: Татарстан Республикасы, Мамадыш шәһәре, М. Җәлил урамы 8/28, Телефоннар: 3-19-17, 89172802391**

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең Бөек исемнәре булганга күрә, аны саклап тотуыгыз сорала**

**Баш мөхәррир: Хәбибуллин А.М. Мөхәррир урынбасары: Хәбибуллина Э.Р.
Дизайн һәм верстка: Мингалиева Ф.Н. Җаваплы сәркатип: Спиридонова А.С.
Безнең адрес: Мамадыш шәһәре, Муса Җәлил урамы,8/28. mamadysh-medrese@mail.ru. Газета "Татмедиа" ААҖнең Мамадыш муниципаль районы"Нократ" мәгълүмат-матбугат филиалында басылды. Тираж татар телендә 400 данә.**